| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕКАЙБИЦКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КАЙБЫЧ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 03 март ОлыКайбыч ав. № 4

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга, шәхси саву аппаратлары сатып алу өчен чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының 2020 елга һәм 2021-2022 елларның план чорына Олы Кайбыч авыл җирлеге бюджеты турында»гы 2019 елның 13 декабрендәге 29 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Советы карары нигезендә, өч һәм аннан күбрәк сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сөт сыерларын тотуга чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү максатларында Олы Кайбыч авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга Олы Кайбыч авыл җирлегендә шәхси саву аппаратлары сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү Тәртибен кушымтада каралганча расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://bkaybic - kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Олы Кайбыч авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Б. Сафин

атарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Кайбыч авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2020елның «03» мартындагы
4 номерлы карарына кушымта

# ШӘХСИ ЯРДӘМЧЕ ХУҖАЛЫК АЛЫП БАРУЧЫ ГРАЖДАННАРГА ОЛЫ КАЙБЫЧ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНДӘ ШӘХСИ САВУ АППАРАТЛАРЫ САТЫП АЛУГА ЧЫГЫМНАР ӨЛЕШЕН КАПЛАУГА СУБСИДИЯЛӘР БИРҮ ТӘРТИБЕ

1. Әлеге Тәртип 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге бюджетыннан индивидуаль саву аппаратлары сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр (алга таба - субсидияләр) бирүне регламентлаштыра.

2. Субсидияләр бирү «2020 елга һәм 2021-2022 еллар план чорына Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге бюджеты турында»гы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге Советы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Субсидияләр Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлегендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга бирелә.

4. Субсидияләр шәхси саву аппаратлары сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга бирелә.

5. Субсидияләр:

шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга шәхси саву аппаратлары сатып алуга - өстәлгән бәягә салым (НДС), монтаж һәм транспорт хезмәтләрен исәпкә алмыйча, аларның бәясенең 50 проценты күләмендә түбәндәге шарт белән бирелә:

субсидия бирүгә гариза белән мөрәҗәгать итү датасына торышы буенча ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуның хуҗалык кенәгәләрендә чагылыш тапкан 3 һәм аннан да күбрәк савым сыеры булу, 3-8 савым сыеры исәбендә бер саву аппараты булу.

6. Субсидияләр бирү максаты - Олы Кайбыч авыл җирлегенең шәхси ярдәмче хуҗалыкларына ярдәм итү.

7. Субсидияләр алу өчен алучылар түбәндәгеләрне тапшыра:

түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү турында гариза;

сату-алу (поставкалар) шартнамәләренең күчермәләре;

сатып алынган саву аппараты бәясенең кимендә 50 процентын түләүне раслый торган түләү документлары (квитанция, касса чегы йә банк өземтәсе һәм түләү йөкләмәсе);

җиһаз (аппарат) паспорты күчермәләре.

8. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) шәхси саву

аппаратлары алуга субсидияләр бирүгә каралган бюджет акчаларының баш бүлүчесе булып тора.

9.Башкарма комитет акчаларны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган шәхси счетыннан субсидия алучыларга күчерә.

10. Субсидияләр алучылар аны амортизацияләү срогы дәвамында субсидия хисабына сатып алынган саву аппаратларын читләштерергә хокуклы түгел.

11. Субсидия исәбеннән алынган саву аппаратын амортизация срогы тәмамланганчы нәтиҗәле эксплуатацияләүне исәпкә алу һәм тикшереп тору башкарма комитет тарафыннан тәэмин ителә.

12. Бирелгән субсидияләр Олы Кайбыч авыл җирлеге бюджеты кеременә әлеге Тәртиптә билгеләнгән максатларны һәм аларны бирү шартларын бозу, субсидияләрне максатчан билгеләнеше буенча файдаланмау һәм (яисә) ялган белешмәләр һәм субсидияләр алу документлары тапшыру буенча файдаланмау фактларын ачыклап, тиешле таләп алынган көннән алып 60 көн эчендә кире кайтарылырга тиеш.

13. Олы Кайбыч авыл җирлеге бюджеты кеременә ирекле кире кайтарылудан баш тарткан очракта, алар законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

14. Алучылар тарафыннан тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә алучыларга йөкләнә.

15. Бюджет акчаларыннан максатчан файдалануны Олы Кайбыч авыл җирлеге Башкарма комитеты тикшереп тора.